# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**27 ноябрь 2024 ел** **№2**

2025 елда Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы Уразай
авыл җирлеге Уразай торак пунктында
гражданнардан үзара салым кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Уразай авыл җирлеге Уразай торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1.2025 елда 1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, махсус хәрби операциягә мобилизацияләнгәннәрнен гаилә эгъзаларыннан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен 150 сум күләмендә, Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Уразай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформаторларны һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны( Уразай белән урамнарны яктырту җайланмасын)ремонтлау;
- Уразай авылы чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (автомобиль юлын ремонтлау, су үткәрү торбаларын урнаштыру Подгорная, Речная урамнарында);
- Уразай авыл җирлеге территориясен төзекләндерү (чүп үләнен чаптыру, чүп-чар җыю, балалар мәйданчыкларын, ял итү зоналарын карап тоту, автомобиль юлын кардан чистарту);
-Уразай авыл җирлеге территориясендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (мотопомпа, янгын җиһазләре сатып алу).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Уразай авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы ____________ А.М.Шәрифуллина
Уразай авыл җирлеге башлыгы (имза) (имза расшифровкасы)